**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Миляшкай» Олы Кайбыч балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе**

**Рания Фаил кызы Гомәрованың**

# Иҗади эш тәҗрибәсе

# ӘЙДӘГЕЗ, ТАНЫШ БУЛЫЙК!

Хәерле көн, дуслар!
Исәнмесез!



Рания Фаил кызы
Гомәрова

* Сәлам белән башлыйм сүземне.
* Таныштырыйм дип чыгып бастым, ләкин
* Читен икән мактау үзеңне.

* Рания Фаил кызы булам,
* Килдем Кайбыч авылыннан.
* Ел тәрбиячесе бәйгесенә
* “Миләшкәй” бакчасыннан.

* Гади генә бер кеше мин үзем,
* Гади түгел ләкин һөнәрем.
* “Тәрбияче” дигән олы исем йөртәм,
* Шул исемне аклау - теләгем.



- «Миләшкәй» бакчасында
- Уз хезмәтемне куям.
- Эшемне бик яратканга
- Эшләве җиңел миңа.



- Табигатьнең гүзәллеген тоя беләм,
- Хисләр җылылыгын сабыйларга бирәм.
- Һәр нәнине нәфис гөлдәй күрәм,
- Шул гөлләргә йомшак сулыш өрәм.

# Балаларга булган мәхәббәтем тәрбиячелек эшемдә миңа зур көч бирә.



* Хезмәтемнең сукмагыннан
* Барган чакта тиз-тиз атлап.
* Гаделлек һәм таләпчәнлек
* Йөртә мине һаман саклап.
* Җиңел түгел барыр юлдан,
* Тиз-тиз генә алга атлап.
* Зилзиләләр көтеп тора
* Борылышта мине кайчак.
* Көтеп тора борылышта
* Авырлык та, киртәләр дә.
* Шатлыгы да бу тормышта.
* Нәтиҗәмне күрим диеп,
* Ялгышып та куям кайчак.
* Төзәтеп шул хаталарны,
* Алга таба атлыйм һәрчак.






Тәрбияче һөнәрен төрле кеше төрлечә аңлый. Минемчә, тәрбияче, иң беренче чиратта, бала күңелен аңлый белүче изге йөрәкле, ата-анага төпле киңәш бирүче педагог булса, икенчедән, ул мөстәкыйль фикер йөртергә сәләтле ирекле шәхес формалаштыручы остаз да булырга тиеш.

* Һәр тәрбияченең үз язмышын балалар бакчасы белән бәйләве дә төрлечә. Берәүләр балачактан ук үзләрен бу һөнәргә багышлаячакларын тоемлыйлар һәм шуңа омтылалар, әзерләнәләр. Икенчеләр исә балага белем бирү, аны олы тормыш юлына әзерләү кебек изге эшкә очраклы рәвештә кереп китәләр.
* Мин үземне шуларның беренчесенә кертер идем. Педагоглар нәселеннән түгел мин, шулай да нишләптер кечкенәдән үк минем хыялым - тәрбияче булу иде.
* Менә инде мин – тәрбияче. Балалар бакчасына барыр алдыннан мин балаларымның һәрберсен күз алдымнан үткәрәм, аларның күңел дөньясын ачарга, ышанычларын акларга тырышам. Кәефем нинди булуга карамастан, алар янына ачык күңел белән керәм, чөнки баланың сизгер йөрәген алдый алмыйсың. Аның күңеленә кешелеклелек, игелеклелек орлыклары салырга җыенасың икән, иң беренче чиратта үзең үрнәк булырга тиешсең.
* Нинди генә заманда, кайсы гына вакытта эшләмә , тәрбиячеләр алдында зур бурычлар , яңадан – яңа таләпләр куела . ФГОС программасы белән танышып үткәч, мин яңа стандартларның “Укырга өйрәтү”, “Яшәргә өйрәтү” һәм “Эшләргә өйрәтү”, “Бергә эшләргә өйрәтү” икәнен аңладым. Чөнки яңа стандартлар буенча эшләгәндә балаларның белем дәрәҗәсе бермә-бер үсә, логик яктан фикер йөртергә өйрәнә, максатка ирешергә омтылышы барлыкка килә.
* Шушы дүрт этап бер берсе белән бәйләнеп барырга тиеш, шул очракта гына алдыбызга куелган бурычлар камил дәрәҗәгә ирешә ала.

# Мин үземнең методик темам итеп “"Серле туп" белән хәрәкәтле уеннар” дигән теманы алырга булдым.



**Туп – туп, тубыбыз,**
**Сикерәбез, көләбез,**
**Югары оч, түбәнгә төш,**
**Без тотып өлгерәбез.**

* Методик теманың уңышлы булуы анын нәтиҗәлелегенә бәйләнгән. Ә нәтиҗәдә баланың физик яктан үсүе, туп белән курыкмыйча, җитез уйный белүе тора.
* Эзләнү эшемнең максатлары һәм бурычлары түбәндәгеләр: балаларда туп чыгышын, халык ара туп белән күп төрле уеннар уйнарга өйрәнүгә карата кызыксыну уяту, җитезлек, тизлек һәм иҗади сәләтләрен үстерү.

# «Тылсымлы туп» – минем ярдәмчем.



Булат, сиңа бирәмен,
Әйдә, уйныйбыз бергә.
Кирәк аны, чөеп – чөеп,
Тотып ала белергә.


* Тупны “тылсымлы” дип әйтүнең мәгънәсен аңлатып үтәсем килә. Мин тупны гадәттәгечә “тылсымлы таяк” урынына кулланам. Балаларга бу яңалык бик ошап китте. Шөгыльләрем нәтиҗәле уза башлады.
* Санарга өйрәнгәндә, сөйләм телендә – сорауларга аерым җавап бирергә өйрәтүдә, физик яктан - җитез булуда, кулларны ныгытуда – туп минем ярдәмчем.
*





**1-2-3-4-5!**

# Бала әти-әнисе белән аралашудан  шатлык ала



**Туп сикерә, син дә сикер,**
**Тыпыр – тыпыр тыпырда,**
**Дуслар белән уйна бергә, .**
**Читтә генә утырма.**

* Максатларыма ирешүдә әти-әниләр дә катнаша. Димәк, бала әти-әнисе белән аралашудан да шатлык ала. Шул рәвешле балалар күңеленә күпер салына. Бала әнә шулай итеп ачыла бара, әти-әнисенә карата ихтирамлык уяна. Үзенә ышануын тойган бала бернинди кыенлыктан да курыкмаска өйрәнә. Баланың яшерен талантын ачу, аңа ышаныч белдереп, катлаулырак эшләргә тарту аңарда тормышның бар кыенлыкларын җиңәрлек сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итә.

# Мин һәр баланы үз баламдай якын итәм.



Күп еллар буена балалар белән эшләү дәверендә мин бер гыйбарәне исемнән мәңге чыгармадым: “Тәрбияче – үзе тәрбияле булырга тиеш”. Ә тәрбияле булу – ул зур төшенчә. Алтыннан да кыйммәтле булган нәрсә – тәрбияле баладыр. Ата-ана үзенең йөрәк җимеше – баласын безнең кулларга тапшыра. Мин һәр баланы үз баламдай якын итәм. Аларга “улым”, “кызым” диеп эндәшү баланы миңа тагын да якынайта. Үз балаларыма биреп җиткерә алмаган күңел җылысын аларга бирәм, үз балаларымда күрергә теләгән сыйфатларны аларда булдырырга тырышам.



# Балаларның сәләтен үстерү, аларны төрле яклап ачу өчен тәрбияче нинди генә шөгыльләр тапмый.







**Әгәр миннән сорасалар,**
**Бәхет – ни ул, дисәләр.**
**Бәхет – минем балаларым**
**Кеше булып үссәләр.**



